| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬ НЫЙ**<br>**КОМИТЕТ**<br>ЧЕРЕМШАНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 февраль 2021 ел **Чирмешән авылы** **№71**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 589 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе беркетмәсенә (04.01.2001 ел, № ПР-3) туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 589 номерлы карарының 12 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«салым һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычның булмавы турында гаиләнең барлык әгъзаларына салым органы белешмәсе(-ләре)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район башкарма комитеты
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин